**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 132**
**15.04.2020**

Шәһәр Хакименең «Шәһәр өмәсе үткәрү турында» 2020 елның 25 мартындагы М 108 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

Коронавирус инфекциясе таралуга юл куймау максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус инфекциясе таралуга юл куймау чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең 2020 елның 27 мартында «Челнинские известия» газетасының 23 нче санында һәм 2020 елның 1 апрелендә «Шәһри Чаллы» газетасының 24 нче санында басылып чыккан «Шәһәр өмәсе үткәрү турында» 2020 елның 25 мартындагы М 108 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Башкарма комитетка әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев